**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«10» ноябрь 2023 ел Яр Чаллы № 123

16:39:00000:735, 16:39:103601:35 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә су белән тәэмин итү һәм су бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү һәм төзекләндерү («Саулык» сәламәтлек саклау - белем бирү комплексы) максатында халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, 2012 елның 20 июнендәге 13/1 номерлы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районында «Түбән Кама» милли паркы» ФДБУ территориясендә урнашкан 16:39:00000:735, 16:39:103601:35 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә су белән тәэмин итү һәм су бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү һәм төзекләндерү («Саулык» сәламәтлек саклау-белем бирү комплексы) мәсьәләсен карау буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Халык тыңлауларын бер көндә, 2023 елның 15 декабрендә 15.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: ТР, Олы Шилнә авылы, Киров урамы, 55.
3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинны билгеләргә.
4. Проект буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.
5. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Кече Шилнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Тука муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының
2023 елның 10 ноябрендәге 123 номерлы
карарына кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

Әлеге тәртип укай муниципаль районында «Түбән Кама» милли паркы» ФДБУ территориясендә урнашкан 16:39:00000:735, 16:39:103601:35 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә су белән тәэмин итү һәм су бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү һәм төзекләндерү максатыннан эшләнде һәм район гражданнарның мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы электр челтәре хуҗалыгы объектларын урнаштыруны билгеләү буенча халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.
2. Проектның график һәм текст материаллары күргәзмәсе Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында оештырылган.
3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе - җомга 9.00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).
4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatar.ru) урнаштырылырга тиеш.
5. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2023 елның 15 ноябреннән 2023 елның 14 декабренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.
6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.
7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.
8. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.
9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
   - чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
   - проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр;
   - фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.
10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан проект буенча халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла.
11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:
   - халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме;

- халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;
- халык тыңлауларында катнашкан гражданнарның саны;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул халык тыңлаулары беркетмәсе белән бергә мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында, Кече Шилнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.